Лаеш шулпасының шулпасы гына булмасмы?

Татарстан Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте базасында күчмә утырыш уздырды. Анда катнашучылар Казан федераль университетының, шул исәптән ректор Илшат Гафуровның «тетмәсен тетте». Республика югары уку йортлары кыйбласы булган КФУның Мәгариф һәм фән министрлыгы алдында нинди гаебе бар соң?

4 БИТ

Нурия Ирсаева:

«Битарафлыкны куралмыйм»

«Тирә-юньдәге битарафлыкны куралмыйм. Кешеләрнең туң йөрәкле булуына борчылам. Үзем урамда исерек йоклап ятса да, аны барып уятуны да оятка санамыйм».

7 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Җомга | 14.04.2017 | № 40 (5802)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

«МОНДЫЙ ФАТИРНЫ ТӨШЕМДӘ ДӘ КҮРГӘНЕМ ЮК ИДЕ»

«Салават күпере»ндә өй туе

«Салават күпере» торак комплексында кичә күптән көтелгән вакыйга булды. 13 апрель көнне 13нче кварталдан беренче йорт кулланугa тапшырылды. Бу очраклылыкны Дәүләт торак фонды хезмәткәрләре үзенә күрә бер билге дип кабул итте.

Эльвира МОЗАФФАР

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

2017 елда авария хәлендәге торакларда яшәүче 5 мең кеше, 47 күп балалы гаилә, 90 яшь гаилә, 305 ятим бала, 76 Бөек Ватан сугышы ветераны, социаль ипотека программасында катнашучылар Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды аша торaклы булыр дип ниятләнелә.

– Социаль ипотека программасы буенча фатир отучыларга, предприятие хезмәткәрләренә, Бөек Ватан сугышы ветераннарына, күп балалы гаиләләргә, авария хәлендәге торакларда яшәүчеләргә – барлыгы 255 кешегә яңа фатир ачкычлары тапшырыла. Чират тудырмас өчен, ачкычларны 30 көн дәвамында алырга мөмкин. Бу вакыйга шәһәр өчен дә зур бәйрәм. Мондый мөмкинлекләр тудырган өчен социаль программаларны тормышка ашыруда ярдәм күрсәтүче Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка, йортларны сыйфатлы, уңайлы итеп җиткергән «Ак таш» оешмасы хезмәткәрләренә зур рәхмәт әйтәсе килә, – диде Дәүләт торак фонды башкаручы директор урынбасары Булат Гыйльманов.

– Үз гомеремдә сигез торак алыштырырга туры килде, соңгы көннәрдә кызым, киявем белән яшәдем. Ниһаять, үз фатирыма аяк басам. Ул шундый якты, матур, зур. Мондый фатирны төшемдә дә күргәнем юк иде, – ди 93 яшен тутырып килүче Гөлҗиһан Яблокова.

Ул – Саратов якларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераны хатыны. Хәер, үзе дә сугыш газапларын аз кичермәгән. 14 яшеннән колхозда эшләргә, трактор йөртергә туры килгән аңа. «Эшләп кеше үлми, гомер буе куйган хезмәтемнең әҗередер бу фатир. Без күргәнне Ходай сезгә күрсәтмәсен, сугышлар булмасын. Тынычлыкта яшик», – дип, теләкләрен җиткерде ул фатирын караганда.

Ткачевлар гаиләсе дә өч бүлмәле фатирларына сөенеп туя алмый. Әле яңа гына тәпи киткән кызлары Ариэлла фатир ачкычларын кулыннан да төшерми.

→ Ахыры 2нче биттә.

Казан бюджетының «алтын койрыгы»

Кешеләрнең «кара көнгә» дип беркадәр акча туплап кую гадәтләре – мактаулы гамәл. Шәһәр казнасында акча запасы булу – монысы инде тагын да куанычлырак.

Автор фотосы

Дамир БӘДРИЕВ

Бу атнада мэр Илсур Метшин рәислегендә Казан шәһәр Думасының XV сессиясе эшләде. Шәһәр Башкарма комитетының финанс идарәсе җитәкчесе Радик Шафигуллин докладында әйтелгәнчә, узган ел шәһәр бюджетында чыгымнар – 21 миллиард 824 миллион, ә керемнәр 22 миллиард 405 миллион сумны тәшкил иткән.

– Салымнар 135,5 миллиард сум җыелды. Бу, 2015 ел белән чагыштырганда, 15,8 процентка күбрәк. Нәтиҗәдә 914,6 миллион сум керем, өстәмә табыш сыйфатында, 2017 ел бюджетына өстәлде, – диде Радик Шафигуллин.

Узган елдан быелга күчкән 914,6 миллион сум «алтын койрык»ның 66,2 миллион сумы Самосыр полигонын томалауга (рекультивация) юнәлтелә. Чүплек тавы махсус тышча белән каплана, шуның өстенә балчык түшәләчәк һәм агачлар утыртылачак.

Акчаның 13,4 миллион сумы Казанда 2018 елга җәмәгать транспорты хәрәкәтенең яңа схемасын әзерләүгә тотыла. Шәһәрнең автомобиль юлларын төзүгә һәм төзекләндерүгә – 33,4, ә кече эшкуарлыкны үстерүгә 18,1 миллион сум күчерелә.

СЕССИЯ

– Социаль яклауга мохтаҗ гаиләләрдән 17 424 бала Казан мәктәпләре ашханәләрендә бушлай туклана. Әлеге чыгымнарга 25,4 миллион сум билгеләнде, –диде Радик Шафигуллин.

Узган елгы бюджетка йомгак ясаганда, мэр Илсур Метшин: «Бюджет кытлыгы кичерелсә дә, Казанда бер генә социаль программа да туктап калмады», – дип, бюджет үтәлешенә уңай бәя бирде.

Казанның 2017 елга бюджет чыгымнары 19 миллиард сум, ә керемнәр 20 миллиард сум чикләрендә билгеләнде. Фаразланган саннарга тормыш үз «төзәтмәләрен» кертергә мөмкин, әлбәттә. Ел башында Казанның муниципаль бурычы 29,8 миллиард сумны тәшкил иткән. Узган ел бурычның 338 миллион сумы түләнгән. Муниципаль бурычның 25 миллиард сумы – бюджет кредитлары, ә 4,8 миллиард сумы – коммерция банкларыннан алынган кредитлар.

Татарстан башкаласында 2014-2016 елларда 1 миллиард 690 миллион сумга муниципаль милек хосусыйлаштырылган. Казанда муниципаль милек сыйфатында 3 385 гектар җир кадастр исәбенә куелган. Шуның 20 проценты коммерция максатларында файдалануга бирү ниятләнелә.

Казанда урамнарны яктырту утлары – 80 мең, электр челтәренең гомум озынлыгы – 2 600 километр. Узган ел бистәләрдәге 21 урамга электр яктырткычлары куелган. Баганаларда терекөмешле лампаларны куллану акрынлап бетерелә, быел шундый 6 мең лампа гамәлдән чыгарылачак.

– Бистәләр урамнарына, паркларга электр яктырткычлары урнаштыру дәвам итәчәк. Кызганыч,шәһәр бюджеты бу эшләрне колачлы рәвештә алып барырга мөмкинлек бирми. Бистәләр урамнарын яктыртуга Татарстан бюджетыннан финанс ярдәме күрсәтелсә, яхшы булыр иде, – дип, фикерләре белән уртаклашты Казан муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин.

Шәһәр хуҗалыгына кагылышлы башка мәсьәләләрне караганнан соң, сессия үз эшен тәмамлады.

«Мондый фатирны төшемдә дә күргәнем юк иде»

→ **Ахыры. Башы 1нче биттә.**

– Алты ел көттек бу фатирны. Ирем – спорт мәктәбендә баскетбол буенча тренер. Бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең социаль ипотека программасында катнаша алуы сөендерә, әлбәттә. Моңа кадәр каенана фатирының 12 квадрат метрлы бер бүлмәсендә яшәдек, хәзер дүртебезгә – 80 квадрат метр мәйдан. Иң зур бүлмәләрне ике балабызга бирәбез, кайда нәрсә урнаштырасын инде күзаллап чыктык, – ди Анжелика Ткачева.

Шархынуллиннар гаиләсе моңа кадәр вакытлыча фатирда яшәгән. «Үз куышың булу – зур бәхет. Яшьләргә тораклы булуда шундый мөмкинлекләр тудыру – бик яхшы», – дип сөенә алар.

13-1нче йортта социаль ипотека программасы буенча төзелә торган торакларда беренче тапкыр заманча исәпләү җайланмаларын сыныйлар. Гадәттә, исәпләгечнең күрсәткечләрен ай саен кәгазьгә язып тапшырырга туры килсә, монда барлык мәгълүматлар да махсус чыбыклар аша идарәче компаниягә барып ирешә. Киләчәктә бу җайланмаларны чыбыксыз итәргә дә уйлыйлар икән.

– Тиздән комплекста 10-5 йорты әзер булыр дип көтелә. Хәзер анда кимчелекләрне төзәтү, документ рәсмиләштерү эшләре белән мәшгульләр. Сентябрьгә кадәр «Салават күпере» торак комплексындагы барлык йортларда да өй туйлары гөрләр, дип ышандыра җитәкчеләр.

Роспотребнадзорның Татарстан идарәсенә юлланган түләүле медицина өлкәсенә кагылышлы шикаятьләр саны соңгы өч елда өч тапкырга арткан. Кешеләр табибларның төгәл мәгълүмат бирмәвеннән, стоматология өлкәсендәге хезмәтләрдән канәгатьсезлек белдерә. Иң күп мөрәҗәгатьләр косметология тармагындагы тәртип бозуларга карый.

Бушлай тикшерәбез дип шалтыратсалар

– Соңгы елларда кешеләр табибларга караганда төрле ташламалар белән кызыктырган оешмаларга күбрәк йөри башлады. Халык төп башына утырту кебек нәрсәләргә саграк карый дип уйлаган идек, әмма алдаланучылар җитәрлек, – ди Роспотребнадзорның Татарстан идарәсендә кулланучылар хокукларын яклау бүлеге җитәкчесе Ирина Әхмәтшина.

Мондый намуссыз компанияләрнең эшләү схемасы гади: телефонга шалтыратып, «безнең оешма дәүләт гарантиясе программасына кертелде һәм сез бушлай медицина тикшерүе уза аласыз. Үзегез белән паспорт, мәҗбүри медицина иминияте полисын алып килегез», диләр. Аннары, имеш, тикшерү уздырган булып, пациентка бер кочак диагноз куялар. Шул авыруларны дәвалау өчен, үзләренең «нәтиҗәле» препаратларын тәкъдим итәләр. Килешүгә кул куйдыралар. Ахырдан кеше бу хезмәтләрне үзе өчен кирәк түгел, түләргә акчасы да юклыгын аңлый. Тик еш кына бу вакытта инде банктан кредит рәсмиләштерелгән була. Әле күптән түгел генә яшәргә теләгән 82 яшьлек әби шул рәвешле 168 меңгә кредит алган. Хәзер 11 мең пенсиясен ничек җиткерергә белми.

– Килешүне өзәргә беркайчан да соң түгел, – ди Ирина Әхмәтшина. – Тик мәнә файдаланган хезмәтләр өчен акча кире кайтарылмый, җыелган процентларны түләүдә дә проблемалар килеп чыга.

– Кече һәм урта эшмәкәрлек белән шөгыльләнүчеләргә бирелгән мөмкинлекләрне үз файдасына куллануучылар бар. Дөрес, мондый медицина оешмаларының лицензияләре бар, әмма күпләр, анда эшләүчеләр клиентларга психологик басым ясый, хәтта анда тәкъдим ителгән чәй дә аңны томалау үзлегенә ия, дип белдерә. Мондый оешмалардан алынган препаратлардан зыян күрүче расланмаган икән, безнең аларны тикшерергә хакыбыз юк. Шуңа да халыкка үзенә сак булырга кирәк, – ди Татарстан буенча Росздравнадзор җитәкчесе урынбасары Любовь Шәйхетдинова.

Эльвира МОЗАФФАР.

vk.com

ӘГӘР БУШЛАЙ МЕДИЦИНА ЯРДӘМЕ КҮРСӘТӘБЕЗ ДИП ШАЛТЫРАТСАЛАР:

шалтыратучыга мөмкин кадәр күбрәк сорау бирегез: төпченегез, лицензияләре белән кызыксыныгыз;

дәүләт гарантиясе программасына кергән медицина оешмалары исемлеген Росздравнадзор сайтыннан тикшерергә була;

тикшеренергә барырга уйласагыз, паспортыгызны өйдә калдырыгыз;

документларга кул куйганда, кат-кат тикшерегез.

Урамда акча алмаштырмагыз

КЕШЕ ҺӘМ ХОКУК

Автор фотосы

Каршыгызга елап килсәләр дә, әллә нинди кызыктыргыч тәкъдимнәр әйтсәләр дә, урамда акча алмаштырмагыз. «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә хокук сакчылары әнә шундый кисәтү ясады.

– Россиядә генә түгел, чит илләргә туристлык сәяхәтләре вакытында да бу кагыйдәне онытмагыз. Сезгә ялган акча тоттырып китүләре ихтимал, ә моның ахыры бик күңелсез тәмамланырга мөмкин, – ди Казан шәһәре буенча эчке эшләр идарәсенең икътисади иминлек һәм коррупциягә каршы көрәш бүлеге хезмәткәре Илгиз Әминов.

Ялган акча ясаган, аны саклаган, ялган акча белән исәп-хисап үткәргән өчен, Россиядә кеше 16 яшьтән үк җинаять җаваплылыгына тартыла. Бу төр җинаять өчен 5 елдан 15 елга кадәр иректән мәхрүм итү һәм бер миллион сумга кадәр административ штраф каралган.

Казанда быел ялган акча белән исәп-хисап ясауның 81 очрагы теркәлгән. 64 берәмлек – 5000 сумлык, тугыз берәмлек 1000 сумлык һәм бер 500 сумлык акча әйләнештән алынган. Аеруча 5000 сумлыкларга карата сак булу сорала. Узган ел Казанда 337 берәмлек 5000 сумлык ялган акча фаш ителгән.

– Ялган акчалар безгә Мәскәү өлкәсеннән килеп эләгә. Быелның мартында Чиләбедән 24 яшьлек һәм Ноябрьскидан 21 яшьлек ике кеше Казанда ялган «биш меңлек»ләр тараткан, – дип сөйләде Илгиз Әминов. – Алар кәрәзле телефон, башка сәүдә кибетләрендә азык-төлек, чәчәкләр сатып алганда ялган акчалар белән түләгәннәр. Әлеге җинаятьчеләр Чиләбе шәһәрендә кулга алындылар.

Казан шәһәре буенча эчке эшләр идарәсенең эксперт-криминалистика бүлеге эксперты Наталья Мезенцева 2004 елгы чыгарылыш акчаларга сак булырга киңәш итте.

– Ялган акчалар күбрәк шушы ел чыгарылышында ясала, – диде Наталья Мезенцева. – 2010 ел чыгарылышыннан республикада әлегә бер берәмлек тә ялган акча фаш ителмәде. Чөнки 2010 ел чыгарылышындагы 500, 1000 һәм 5000 сумлык акча берәмлекләре көчәйтелгән сакланыш элементлары кулланып эшләнгән. Аларны кул астындагы аппаратлар белән өй шартларында ясау гомумән мөмкин түгел.

Ялган акча белән исәп-хисап үткәрүләр күбрәк базарларда, кәрәзле элемтә салоннарында, сәүдә киоскларында, тиз туклану рестораннарында очрый.

Дамир БӘДРИЕВ.

КУЕН ДӘФТӘРЕНӘ

✓ Таныш булмаган кешеләргә акча ваклап бирмәгез;

✓ күчемсез милек яки автомобиль сатудан алачак зур күләмдәге акчаны башта банкта тикшертегез;

✓ чит илдә урамда валюта алмаштырмагыз;

✓ кулыгызга ялган акча кергәнлеген сизсәгез, аны исәп-хисап үткәреп җибәрергә тырышмагыз, бу инде җинаять эшләүгә санала, шунда ук полициягә мөрәҗәгать итегез;

✓ базарда әйбер сатып алганда, кайтарып бирелгән акчаларны игътибар белән тикшерегез;

✓ банкоматтан акча чыгартып алганда, банкоматның чеген ташламагыз, ә билгеле бер вакыт саклагыз;

✓ ялган акча белән эш йөртергә җыенучыларны сизеп алсагыз, «02» телефоны аша кичекмәстән полициягә хәбәр бирегез.

Татар теленә өйрәтүче «Ана теле» онлайн мәктәбе быел биш еллык юбилеен билгеләп үтә. Шушы кыска гына вакыт эчендә ул 49 мең кешене Тукай теленә өйрәтүгә ирешкән.

«Ана теле» өметне аклады

Россия төбәкләреннән тыш, сайтта 57 чит илдән 1700 кеше теркәлгән. Аеруча Казахстан, Австрия һәм Австралия татар телен актив өйрәнә икән. Араларында читтә яшәүче татарлар гына түгел, ә татар тормышына бер катнашы булмаган кешеләр дә очрый. Әйтик, онлайн-мәктәп аша Испаниядә яшәүче Бернард Монод татар теле белән кызыксынып киткән.

– Ул, гомумән, кызыклы шәхес. Милләте буенча француз кешесе, Испаниядә яшәп, төрек теле белгече булып эшләгән. Лаеклы ялга чыккач, тагын бер төрки тел үзләштерү максатыннан, татар телен өйрәнә башлаган, – ди Казан федераль университетында «Ана теле» онлайн-мәктәбе үзәге директоры Кадрия Фәтхуллова.

«Ана теле» – 9 баскычлы белем бирү системасы. Ул 72 бүлек, 288 дәрес, 6372 күнегү, 293 видеосюжет, 10950 аудиофайл, 6795 фотографиядән тора. Сүзнең тәрҗемәсен аңламасаң, онлайн-сүзлек ярдәмгә килә. Казан университеты базасында 17 сәгатьтән 21 сәгатькә кадәр сөйләм дәресләре алып барыла. Тел белүче кешеләр белән интернет аша аралашу сөйләм арасындагы барьерны бетерә. Һәр дәрәҗәне узган кешегә белем алуы турында сертификат бирелә.

– «Ана теле» проектын төзегәндә, без велосипед уйлап тапмадык. Инглиз телен өйрәтү буенча 300 еллык тәҗрибә бар, шуңа таянып эшләдек. Дәресләрне кызыклы һәм үтемле итәргә безгә телләр өйрәтү буенча дөньякүләм танылган EF Education First оешмасы ярдәм итте. Шушы биш ел эчендә «Ана теле» өметләребезне аклады, – ди Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры урынбасары Илдар Мөхәммәтов.

Онлайн-мәктәптә уку елы февраль аеннан башланып, бер ел дәвам итә. Дөрес, интернет аша тел өйрәнгән вакытта күп әйбер укучының үзеннән тора. Ялкаулык дигән төшенчә дә бар бит әле. Моны булдырмас өчен, проект җитәкчеләре ел саен апрель аенда иң актив укучыларны бәяли икән.

Укулар февраль аенда башлана дисәк тә, проект җитәкчеләре әлегә резерв буларак 200 урынны саклап тоткан. Шушы көннәрдә татар телен үзләштерергә теләгән кешеләр «Ана теле» проектына кушыла ала.

Алисә САБИРОВА.

8 апрельдә узган «Тотальный диктант»та республика буенча 3512 кеше катнашкан. Казанда диктант язучыларның саны быел 1370кә җиткән, аларның 51е «бишле» алган, бу гомуми санның 4 процентын алып тора. «Бишле» алучылар арасында Татарстан Президентының ярдәмчесе Олеся Балтусова да бар. Татарстанның рус милли-мәдәни берләшмәсе рәисе урынбасары Ирина Александровская сүзләренчә, акциядә катнашучылар аеруча «мороженое молоко» сүзтезмәсендә, «пьедестал» һәм «исполин» сүзләрендә хаталар җибәргән.

Балтусовага – «биш»ле

– Гомумән алганда, акциядә катнашучыларның саны елдан-ел арту, аның үзенә төрле милләт кешеләрен җәлеп итүе сөенечле. Диктант язарга 70 яшьлек әби-бабайлар да, гаиләләре белән килүчеләр дә бар иде. Районнарда яшәүчеләр дә кушылды акциягә, быел 23 муниципаль берәмлек катнашса, киләсе елга калганнары да җәлеп итәлер дип уйлыйм, – дип сөйләде ул журналистлар белән булган матбугат очрашуында.

«Тотальный диктант»ны быел 71 илнең 858 шәһәрендә язганнар. Иң күп катнашучылар Мәскәү (20150), Санкт-Петербург (7184) һәм Новосибирскида (6930). Таллин үзенең «Тондираба» боз сараенда 2973 кеше катнашындагы акциясе белән узган елгы рекордны куйган. Чит илләрдә рус теленнән белемен 18000 кеше тикшергән. Быел ул беренче тапкыр Нигерия, Бангладеш, Гватемала, Исландиядә узган. 23000 кеше диктантны онлайн язган.

Диктант язучылар үзләренең билгеләре белән totaldict.ru сайтында таныша ала.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

Татарстан Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте базасында күчмә утырыш уздырды. Көн тәртибендә һөнәри уку йортларында милли педагогик кадрлар әзерләү мәсьәләсе иде. Утырыш шактый «кызу» барды. Татарстанның мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, Дәүләт Советы комитеты рәисе Разил Вәлиев, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров Казан федераль университетының, шул исәптән ректор Илшат Гафуровның «тетмәсен тетте». Республика югары уку йортлары кыйбласы булган КФУның Мәгариф һәм фән министрлыгы алдында нинди гаебе бар соң?

ҖИТДИ СӨЙЛӘШҮ

Лаеш шулпасының шулпасы гына булмасмы?

Алисә САБИРОВА

Разил Вәлиев сүзләренчә, сыйфатлы укытучылар булмаса, милләтнең киләчәге дә аяныч хәлдә булачак.

– Соңгы елларда мәгарифкә бик нык игътибар бирелә. «Киләчәк», «Бәләкәч» дигән дәүләт программалары уңышлы эшләп килә. Яңа мәктәпләр, балалар бакчалары төзедек. Әмма әле һаман да хәл ителмәгән проблемаларыбыз күп. Безнең төп эшебез укытучыларга юнәлгән булырга тиеш. Укытучы булмаса, күпме генә мәктәпләр төзесәң дә, дәреслекләр, кулланмалар чыгарсаң да, мәгариф алга китмәячәк. Иң беренче чиратта без милли педагогик кадрлар әзерләргә тиеш. Алдыбызда татар телен һәм әдәбиятын үстерү генә түгел, ә фәннәрне дә туган телебездә укыту бурычы тора. Киресенчә булган очракта, ул инде тулы канлы татар мәктәбе түгел, ә лаеш шулпасының шулпасы гына була. Укытучылар гына түгел, тәрбиячеләр дә җитми. Йөзләгән балалар бакчасында бүген әле чын мәгънәсендә татар әдәби телен белгән тәрбиячеләр бар дип әйтә алмыйбыз. Бүген без җыелган Арча педагогия көллияте нәкъ менә милли кадрлар кытлыгын киметү юнәлешендә эш алып бара, – диде депутат.

Энгель Фәттахов исә чит илләрдә мәгариф торышын сөйләп китте. Әле яңа гына ул Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән Калифорния штатында кадрлар әзерләү системасы белән танышып кайткан.

– Бездәге материаль-техник база башка илләрдән бер дә аерылмый, аларны куллану мөмкинлеге генә үзгә, – ди ул.

Министр «югары уку йортын тәмамлаган һәр яшь белгеч сертификация үтәргә тиеш» дигән актуаль мәсьәләгә басым ясады. КФУ исә бу таләпләрне бик үк үтәп бетерми икән.

– Укытучы мәктәпкә кулына диплом белән сертификат та тотып килергә тиеш. АКШта да, Сингапур, Финляндиядә дә шулай. Без – кадрларга заказ бирүче! Белем бирү сыйфаты өчен без җавап тотабыз. Бүгенге яшь кадрлар сертификация таләпләренә туры килми. Узган елны яшь белгечләр үз теләге белән сертификация үтте. Иң «йомшак» югары уку йорты булып Алабуга институты танылды. Биредә укып чыккан 127 кешенең 43е генә сертификатка дәгъва кылды, ләкин 16 кеше генә аны алуга иреште. Ни кызык, КФУны тәмамлаган 329 студентның бары 43е генә сертификация үтүдән курыкмады. Аларның 51,1 проценты гына тиешле балларны җыя алды. Бу уңай күренеш түгел. Быел исә без педагогларга карата сертификацияләүне мәҗбүри рәвештә кертәчәкбез, шулаймы, Рияз Гатауллович? – дип мөрәҗәгать итте Энгель Фәттахов Казан университетының беренче проректорына.

– Быел булмый, инде вакыт үтте, – дип кызарды университет проректоры Рияз Минзарипов.

– Мин бу утырышка Илшат Гафуров килер дип әзерләндем, ләкин ул юк, – дип сүзен дәвам итте министр.

Таякның юан башы тулысы белән Рияз Минзарипов башына төште. Ректор исә бу мизгелләрдә университетларның Евразия ассоциациясенең киңәйтелгән утырышында чыгыш ясый иде.

Уку йортын тәмамлаган педагоглар сертификациядән качарга тырышса да, аның уңай яклары да күп булуын ассызыклады министр. Сертификатлы яшь укытучының хезмәт хакына ай саен тагын 10 мең сум акча өстәлеп бара икән.

– Сан ягыннан укытучылар җитә, ә сыйфат ягыннан аксый. Иң мөһиме – милли кадрлар әзерләү. Соңгы вакытта федераль үзәк бюджет урыннарын кыскарта. Хәзерге вакытта КФУда инде биология, музыка, ОБЖ фәннәре буенча укытучылар әзерләмиләр. Әлеге белгечлекләр Алабугага күчерелде. Бу дөрес әйбер түгел! Казан – безнең башкалабыз, укытучылар әзерләү буенча төп эш биредә башкарылырга тиеш. Бигрәк тә ике телле мохиттә эшли ала торган кадрларга кытлык, – диде министр, Казан университеты бакчасына тагын бер таш атып.

Проректорның да җавабы көттермәде.

– Татар филологиясеннән тыш, башка фәннәр буенча татар телле белгечләр әзерләү федераль канун нигезендә каралмаган. Бюджеттан акча бары татар филологиясе белгечлегенә генә бүлеп бирелә. Республика бюджеты хисабына милли кадрлар әзерләү исә бөтенләй мөмкин түгел, – диде Рияз Минзарипов.

Министр КФУда даими рәвештә немец теле төркеме өчен бюджет урыннары артыруын да искәртеп китте.

– Немец теле урынына татар теле төркемен җыеп булмыймы соң? – дип сорау бирде ул.

– Бездә немец теле мәктәбе көчле, без аннан баш тартырга тиешме хәзер? – дип, сорауга сорау белән җавап кайтарды Рияз Минзарипов.

Шулай да республика хәзер максатчан рәвештә ике телдә укытырга сәләтле укытучылар әзерли башлады. Студентларга ай саен 15 мең сум стипендия дә түләнә. Бу программа буенча КФУда бүген 183 студент белем ала, шуларның 57се дәресләрен бары тик татар телендә генә алып барачак. Ләкин университетның бу эше белән дә канәгать түгел министр. Баксаң, уку йорты тарафыннан әлеге укучыларны бергә туплап торучы бер җаваплы кеше дә билгеләнмәгән икән.

– 183 кешенең һәрберсе университетның төрле биналары буенча таралып беткән. Без аларны шул биналар буенча үзебез шалтыратып эзләп йөрергә мәҗбүр. Әле без 15 мең стипендия түләп укыткан студентлар арасында «өчле»гә укучылар да бар икән! Андыйлар 23, без аларны укудан төшереп калдырачакбыз. Бу – педагогик элитаны булдырасы кешеләр, – диде Энгель Фәттахов.

Һәр укытучы да өч елга бер тапкыр квалификациясен күтәрә. 2017 елда моның өчен республика бюджетыннан 100 миллион сум акча бүленгән. Бу акчаларның 37 проценты КФУга тапшырылган.

– Ректор, безне ришвәтчелектә гаепләп, шул 100 миллионның барысы да КФУга бирелергә тиеш иде дип белдерде. Безне сезнең эш канәгатьләндерсә, бу акчаларның барысын да сезгә бирер идек. Сездә укытучылар Роторный урамындагы элеккеге тулай торакта квалификация үтә! Педагоглар КФУның базасын да, лабораторияләрен дә күрми. Аларның нибары 20 проценты гына КФУда белемнәрен арттырырга тели. Акча сораганчы, башта үзегездә тәртип салып бетерегез, – диде Энгель Фәттахов.

Алабуганың педагогика юнәлешендә йомшак булуын сәбәп итеп, Энгель Фәттахов укытучылар әзерләүне Казан белән Чаллыга гына калдырып, Алабугага бөтән юнәлеш биреп булмыймы соң, дип сорады. Проректор исә: «Барысы да Илшат Гафуров карамагында», – диде. Һәрхәлдә, ректор Алабуганы нәкъ менә укытучылар әзерләүче үзәк буларак күрә икән.

Бу сүзләргә Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров та түзмәде.

– Университетларны берләштергәндә, бер нәрсә дә үзгәрмәячәк, педагогик юнәлешләр ничек эшләде, шулай эшләячәк дигән идегез. Уртак бер фикергә килергә вакыт! Татарлар 100 ел КФУга керә алмады, хәзер 100 елдан соң сез аларны кабат куасыз, – дип чаң сукты ул.

Минзарипов исә: «Без милли кадрларны әзерләдек һәм әзерләүне дәвам итәбез», – дип кенә җавап кайтарды.

КФУ студентларына практика җитмәү мәсьәләсен дә билгеләп китте министр. Студентлар мәктәпләрдә бары 3нче курста гына практика үтә башлый икән. Бу исә яшь укытучы өч-дүрт атна гына үзен мәктәптә сынап карый дигән сүз.

– Бу укытучыда мәктәптән һәм сыйныфтан курку хисе тудыра һәм аларда сайлаган һөнәрләре буенча эшләү теләген бетерә. Хәзер Казан федераль университетында педагогларны биш еллык белгечлек буенча укыту системасын кире кайтару буенча сөйләшүләр бара. Ләкин әлегә ул хәл ителмәгән, – ди Энгель Фәттахов.

– Проблемалар чыннан да күп. Минемчә, КФУ илгә генә түгел, республикага да хезмәт итәргә тиеш. Педагоглар әзерләүдән дә җитдирәк мәсьәлә юк. Бу бүген генә килеп чыккан сораулар түгел, республика күләмендәге мөһим мәсьәләләр. Федераль университет универсаль уку йорты булырга, барлык белгечләрне дә әзерләргә тиеш. КФУ белән Мәгариф министрлыгының максатлары бер булырга тиеш, – дип йомгаклады утырышны Разил Вәлиев.



Бакчачылык ширкәтләренең берсен фотога төшереп йөргәндә, ике бакчачыны очраттым. Танышып сөйләшеп алдык. Роза апа белән Абдул абый алмагач бетенә каршы дару сиптерергә килгәннәр икән. «Безнең монда алманы иртә бирә торган агачлар үсә. Агачлар бөреләнгәнче, дару сибеп өлгерергә кирәк. Бүген җил дә исми, кар-яңгыр да юк – бу эшнең нәкъ вакыты», – дип аңлатты Роза апа үзләренең эшләрен. Сөбханаллаһ, бакча яраткан өлгер кешеләр эшкә дә тотынган.

БАКЧАЛАР ЧАКЫРА

Апрель аеның якты көннәрен көтеп алмаган кеше юктыр ул. Казанлылар әле яз килүенә икеләтә сөенә дисәм дә һич кенә арттыру булмас, минемчә. Язгы кояш нурлары җирне җылыта, бакчаларга юл ачыла. Калада яшәсәк тә, җирне һәм гомумән табигатьне яратабыз без.

Эреле-ваклы дача өйләре быел ничек кышлады икән? Васильево бистәсе полиция бүлеге җитәкчесе **Айрат Шәмсулла улы Хәйруллин** белән шул хакта сөйләштек. Нәкъ менә Васильевоны сайлавымның сәбәбе гади үзе: казанлыларның бакчалары, нигездә, шул якта урнашкан. Төгәлрәк әйтсәк, Идел буендагы бистә җирләрендә хәзерге көндә җәмгысы 98 бакчачылык ширкәте теркәлгән.

– Бистәбездә даими рәвештә 17 мең кеше яшәсә, җәйгә чыккач, халык саны 60 меңгә үк җитә. Казаннан йөри торган шәһәр яны поездына сатылган билетлар саны буенча ясалган исәп-хисап бу. Әле шуңа үз машиналарында йөрүчеләрне дә өстәргә кирәк. Шундый ишле халыкны сыйдырган бакчаларга илтифат итми мөмкин түгел. Һәм анда тәртип тоту безнең төп эшебезгә әйләнә дип тә әйтә алам. Узган елның ноябрь аеннан алып март ае ахырына хәтле, ягъни биш ай вакыт эчендә 13 урлашу теркәлде. Угрылар тотылды: җинаятьчеләр төркеме Казаннан килеп, дача өйләрен басып йөргәннәр.

– Кешегә борчылырга урын бар икән...

– Казанлылар берүк тынычлана күрсен – бу бик аз. Каушап, шау-шу күтәрерлек түгел, Аллага шөкер. Йөзгә якын бакчачылык ширкәтләрендә биш ай эчендә кылынган моның хәтле урлашуны, әйтик, ун-унбиш ел элек анда булган талау-урлаулар белән чагыштырсак, тамчы гына дип тә әйтергә ярый. Ул чакта бакчаларны басучы җинаятьчеләрне авызлыклау максатында, биредә бөтен бер милиция ротасын тотарга мәҗбүр булганнар. Хәлнең кискенлеген шуннан да чамаларга мөмкин,әлбәттә. Йөздән артык сакчы милиция җәлеп ителгән дигән сүз бит бу. Соңгы елларда, тырыша-тырыша, хәлне уңайга үзгәртә алдык без. Җиңел кәсепкә иялашкан угрыларга бакчада хуҗа барлыгын күрсәтергә кирәк. Кисәтү-профилактика алымы, дибез аны үзебезчә. Ягъни урлашу фактлары ачылып, чакырулары көтеп ятмыйбыз, даими рәвештә оператив кизү торабыз. Машина йөрсен өчен, бакчачылыкка илткән төп юллар кардан чистартыла, ширкәт рәисләре белән бу турыда килешенгән. Каравылчылар белән даими элемтә урнаштырылган. Анары участковыйлар да уяу тора. Безнең яктан менә шундый даими игътибар булуын күргәч, кырын эшкә иялашкан бурлар да, кеше җиренә аяк басканчы, кабат-кабат уйлый әле.

– Бакчачыларның нәрсәләренә кызыккан инде караклар?

– Тиз сатыла торган кыйммәтле әйберләрне алырга тырышканнар. Электр инструментлары, бер ноутбук һәм бер телевизор, нержавейкадан ясалган савыт-саба, өч метрлы алюминий баскыч... Беләсезме,биредә минем киңәш тә бирәсем килә. Хөрмәтле бакчачылар, бернічә ай буе беркем дә аяк басмаячак аулак өйләрегездә, зинһар, кыйммәтле әйберләр калдырмагыз – бу дөньяда комсызлар бетмәгән әле!.. Берсе бит хәтта мотоциклын да кышын шунда тотарга ниятләгән. Аны көрт ерып алып китә алмаганнар әлеге угрылар, әмма сүтә башлаганнар. Әгәр аларны безнең кизү торучылар вакытында эләктермәгән булса, теге башсыз үзенең техникасыннан колак каккан булыр иде.

– Айрат Шәмсуллович, хәзер без югалтулар кичергән бакчачыларыбызны куандыра алабыз дип уйлыйм: урланган әйберләрне сез әле генә санап чыктыгыз. Димәк, алар табылган булып чыга?

– Әйе, урланган әйберләрне таптык. Ничек һәм кайда эзләвебезне җентекләп сөйләмәсәм дә ярыйдыр – безнең хезмәтнең оператив сер дип аталган ягы да бар бит әле. Ә менә хуҗаларына кире кайтаруны аерым искә аласым килә. Мәхкәмә карары нигезендә оештырыла бу гамәл. Дөресен генә әйткәндә, шактый мәшәкатьле һәм сабырлык таләп итә торган эш ул. Тапкан әйберләрнең хуҗаларын эзләргә кирәк, ниһаять тапкач, әлеге әйберләрнең аныкымы-түгелме икәнлеген судта тиешенчә исбат итү дә зарур. Мисалга, урланган телевизорны хуҗасына танышу искә кереп калды. Аның хуҗасын Казанда эзләп табып китердек китерүен, әмма ул үзенең телевизорының хәтта маркасын да хәтерләми икән, документациясен дә сакламаган, билгеле. Инде бөтен тырышуыбыз юкка чыга дигәндә, ул адәм үзенең телевизорының үзенчәлекле җитешсезлеген – экранның бер почмагы, эшләгән чагында, кара тап белән капланып исенә төшерде. Телемастер чакыртып кабызып карадык – чыннан да, экран почмагында кара тап килеп чыкты. Хуҗасы шулчак шатланып кычкырып җибәрмәсенме!.. Кайвакыт дефекта да сөенәсең икән шул.

– Аның белән бергә сез дә куангансыздыр – мәшәкатьле эшегез уңышлы тәмамланды дигән сүз бит инде бу. Шулай да тәҗрибәгездән чыгып әйтегез әле: биредәге бакчачылыкта, хуҗалары борчылып киеренкелектә яшәмәсен өчен, тагын нәрсә эшләргә мөмкин?

– Әйтик, йортны, сигнализация челтәренә тоташтырып, сакка куярга була. Бездә шундый мөмкинчелек тә бар. Гомумән, үз әйберенә хуҗа була белергә кирәк. Бусы инде аның тормыштан чыккан кагыйдә.Мин алда киңәш биргән идем – бакчачылар шуны да исләрендә тотсалар, һичшиксез, урлашулар кимер иде һәм бакча хуҗалары үзләре дә тыныч яшәр иде.

Әңгәмәдәш –
Ильяс САЛИХҖАН.

АПРЕЛЬ АЕНДА БАКЧАЧЫ ЭШЛӘРЕ

- **1-7 апрель.** Айның беренче көннәрендә, бөре чыкканчы, агачларны карарга кирәк. Корыган ботакларны кисәргә, ботакларда калган һәм агач төбенә коелган былтыргы яфракларны җыеп алып учакта яндырырга кирәк. Шулай чистарткач, агачның кәүсәсен агартырга ярый. Моның өчен 10 литр су, 2 кило сүндерелгән известь, 200 грамм бакыр купоросы, бер кашык агач клееннан торган катнашма әзерләргә кирәк.
- **10 апрель.** Утыртасы бәрәңгене баздан чыгарып яровойлаштырыр вакыт җитте. Бәрәңге орлыгын кояш төшә торган җылы верандада тотарга ярый.
- **10-15 апрель.** Бу көннәрдә кыяр орлыгын рассадага утыртабыз. Рассада пленка белән ябыла торган парник өчен әзерләнә.
- **10-20 апрель.** Кабак һәм патиссон орлыкларын рассадага утыртабыз.
- **15-20 апрель.** Ачык җирдә үстереләчәк кыяр рассадасын утыртабыз.
- **20-30 апрель.** Карбыз һәм кавын орлыкларын рассадага утыртабыз.
- **15-30 апрель.** Пленка белән ябыла торган түтәлдә яисә теплицада төче торма (редис) чәчәбез.
- **20-30 апрель.** Ачык җирдә ясалган түтәлдә кузгалак, шөет (укроп), сельдерей һәм петрушка кебек аш тәмләткеч үсемлекләрне чәчәбез. Түтәл өстен җәймә белән капларга кирәк.
- **20-30 апрель.** Ачык җирдә түтәл ясап, иртә өлгерә торган кишер чәчәбез.
- **25-30 апрель.** Ачык җирдә борчак һәм ногыт борчагын утыртабыз.
- **25 апрель.** Орлыкка үстерелә торган сарымсак өчен түтәл ясыйбыз.
- **30 апрель.** Помидор һәм кыяр утыртыласы теплицаны әзерләп куябыз.

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең кече залында Татарстанның атказанган артисты Рәшит Гобәйдуллинның тууына – 90, талантлы җырчы Риф Сафиуллинның тууына 80 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе булды. «Илһамият» клубының «Йөрәккә уелган исемнәр» дип аталган искә алу циклы кысаларында узган чарада Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Эмиль Җәлалетдинов, Татарстанның халык артистлары Гөлзадә Сафиуллина, Римма Ибраһимова, Георгий Ибушев, Лариса Маслова, Рабига Сибгатуллина, Фәрит Хатыйпов, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Фәнис Гыйльметдинов, Татарстанның атказанган артистлары Сания һәм Кәрим Габидуллиннар, нәфис сүз остасы Диләрә Ильясовалар катнашты. Кичәне уздыруда башлап йөрүчеләр – Татар филармониясе музее мөдире Алсу Хәкимова һәм Риф Сафиуллинның хатыны, Татарстанның халык артисты Гөлзадә ханым Сафиуллина.

Татар филармониясендә чирек гасыр хезмәт иткән Татарстанның атказанган артисты Рәшит ага Гобәйдуллин – 26, филармониядә биш ел гына эшләп калган Риф Сафиуллин 13 апрельдә дөньяга килгәннәр. Икесе дә лекторий бүлегендә хезмәт куйганнар.

«СИН ХӘТЕРЛӘ МИНЕ»

РИФ САФИУЛЛИН

Вакыт еш кына хәтердән күп вакыйгаларны, шәхесләрне сөртә. Бу ике җырчының тавышы соңгы берничә дистә елда телевидение һәм радиоларда ишетелгән, халык телендә булган дип әйтү хак булмас. Дөрес, Риф Сафиуллинның исеме үзе исән чакта ук кайбер белгечләр тарафыннан «онытылырга тиешле» дип мөһерләнә. Татарстаннан читтә туып-үсеп, татарлар мәркәзенә ашкынып килгән, Казан консерваториясендә профессиональ белем алып, зур сәхнәгә затлы җырчы булып чыккан егет, туры сүзе, гаделлеге аркасында, әнә шулай кара исемлеккә кертелә. Гаиләсенең, балаларының күңеле моңа әлегәчә сыкрамый, дисезме. Халкы алдына чыгып җырлау хокукыннан мәхрүм ителеп, шул үгисетүләр нәтиҗәсендә гомере өзелгән җырчы ул Риф Сафиуллин. Татар филармониясендә, әйткәнемчә, ул бик аз – бары биш ел гына эшләп калган. Филармониянең әдәби-музыкаль лекторий бүлегенә 1968 елда эшкә килә ул. 1972 елда эстрада бүлегенә күчә һәм Әлфия Авзалова төркеме белән барлык Советлар Союзын урап чыга.

Татарстанның халык артисты Гөлзадә Сафиуллина сөйләгәннәрдән: *«Рифне, активлыгын күреп, филармониянең ул вакыттагы җитәкчелеге административ юнәлеш буенча укырга җибәрде. Шул укуыннан ул артистларга хезмәт хакларын ничек арттырып булуы, гомумән, шартларны яхшырту ысулларын белеп кайтып, җитәкчеләргә сөйләде. Ләкин аңа «Артистларга боларны белү кирәк түгел!» дигән шарт куйдылар. Риф моның белән килешмәде. Филармониядән генә түгел, Казаннан да китүебезнең сәбәбе шул хәлләргә бәйле. Ул чактагы Куйбышев филармониясенә барып эшли башлагач та, Рифнең вафатына кадәр, безнең зур популярлык казанган, татарлар яшәгән төбәкләрдә тулы заллар җыеп чыгышлар ясаган төркемебезне Татарстанга һәм Башкортстанга бер тапкыр да кертмәделәр. Мин үземнең туган ягыма кайтасыма, биредә төпләнәсемә барыбер ышанып яшәдем. Һәм кайттым. Риф кайта алмады... Хәзер филармония мине: «Безнеке син, Гөлзадә апа», – дип кабул итә, хөрмәтли. Әлеге кичәне уздырырга да ярдәм зур булды. Татар филармониясенә рәхмәтләрем чиксез».*

Җырчы 1978 елда, инструменталь ансамбльгә кушылып, Куйбышев радиосы фондында Рим Хәсәнов, Алмаз Монасыйпов, Марс Макаров, Сара Садыйкова, Ләбиб Айтуганов әсәрләрен, татар халык җырларын яздыра. Соңрак әлеге язмаларны туплап, Гөлзадә ханым Сафиуллина «Син хәтерлә мине» дип аталган диск чыгара. Дискка «Безнең авыл» (А.Монасыйпов, Г.Тукай), «Шыңгән чәчкәләр»,«Мин табынган күзләр», «Ак чәчәкләр» (Р.Хәсәнов, Ш.Биккол), «Син гомер агышларым»,«Әкълимә» (Р.Хәсәнов, Г.Идрисов), «Тулпар атым» (М.Макаров, Г.Зәйнашева), «Туган авылым Чынлы», «Җилләр тидермәс идем», «Өзелгәнсең сиреннән» (С.Садыйкова, Г.Зәйнашева), «Юллар» (Л.Айтуганов, Ә.Ерикәй), «Керфекләрең синең нигә кара?», «Ак бүрек», «Дим-дим», «Зәңгәр төймә», «Ай, йолдызым»,«Ашхабад» (татар халык җырлары) әсәрләре кергән. Искә алу кичәсендә Гөлзадә ханым әлеге дискны барлык катнашучыларга һәм кунакларга бүләк итте.

РӘШИТ ГОБӘЙДУЛЛИН

Җырчы, Татарстанның атказанган артисты, гаҗәеп баритон тавыш иясе Рәшит ага Гобәйдуллин Татар филармониясенең күз өстендәге каш кебек, хөрмәтле, зыялы җырчысы була. Озак еллар хезмәт куеп, озын матур гомер итеп, 2013 елда Казанда вафат була ул.

Профессиональ музыка сәнгатенә ул да урау юллар аша килеп керә. Үзенең хыялына ирешкәнче, тормышның төрле киртәләре аша үтәргә туры килә. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисты буларак беренче тапкыр чыгыш ясаганда, аңа инде 40 яшь тулган була. Аңа кадәр – җиде елга сузылган хәрби хезмәт – японнарга каршы сугышта катнаша, сугыштан соң эшче яшьләр мәктәбендә урта белем, Казан дәүләт консерваториясенең кичке бүлегендә укып, югары музыкаль белем ала. Рәшит ага ансамбль белән төрле төбәкләрдә гастрольләрдә була, аның данын үстерүгә үз өлешен кертә. Филармониянең музыкаль лекторий бүлегенә эшкә җырчы 1979 елда күчә.

Кичәдә Рәшит ага турында истәлекләр белән бүлешүчеләр күп булды. Һәркайсы сүзен: «Рәшит абый гаҗәеп яхшы күңелле кеше иде...» – дип башлады.

Татарстанның халык артисты Георгий Ибушев сөйләгәннәрдән: *«Рәшит абый белән нинди генә залларда, балалар бакчаларында, мәктәпләрдә чыгыш ясамадык, ул – инде күренекле, затлы җырчы – беркайчан да үзенә аерым шартлар, аерым уңайлыклар сорамады. Шулкадәр тыйнак, тәртипле иде ул. Бервакыт лекторий белән Кукмара итек комбинатында галәмәт зур бер цехта концерт куябыз. Карыйм, цехның бер почмагында өстән «күгәрченнәр» очып керә. Карале, минәйтәм, ничек керәләр икән болар монда, дим. Баксаң, өстәге итек басу цехыннан без концерт куйган цехка итекләр очып төшә икән. Төрле шартларда эшләдек, зарланмадык, кешеләр күңеленә матурлык өләшүебезгә куана идек».*

Татарстанның халык артисты Лариса Маслова сөйләгәннәрдән: *«Әхтәм Зарипов бервакыт озак еллар шахталарда эшләп туган ягына әйләнеп кайткан татар кешесе турында телефильм төшерде. Аның туган ягының ничек матурланганын, яңарганын күреп соклануларын мин виолончельдә уйнаган көй белән бизәде. «Кузләр» музыкаль драмасыннан «Рәйсә җыры» иде ул. Рәшит абый әлеге көйне ишеткәч, миннән аның ноталарын сорады. Утенечен берничә тапкыр кабатласа да, ул чакта мин ул ноталарны таба алмадым. Югалткан идем. Бу кичәгә чакыргач, архивымдагы кәгазьләрне актарганда, әлеге ноталар килеп чыкты. Бүген мин ул көйне Рәшит абый истәлегенә башкарам. Бу – кайчандыр үтәмәгән бурычымны үтәвем булсын».*

Истәлекләр, җырлар, музыка белән уралып барган кичә күңелдә якты да, моңсу да хисләр калдырды. Кичә тәмамлангач, Риф Сафиуллинның һәм Рәшит Гобәйдуллинның туганнары кичәдә чыгыш ясаган «илһамият»челәрне мул табынга чәйгә чакырдылар. Истәлекләр биредә дә дәвам итте. Бакыйлыкка күчкән иҗатчылар рухына дога кылынды...

Зимфира ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА.

МӘДӘНИЯТ

Нурия Ирсаева:

«Битарафлыкны куралмыйм»

Татар һәм башкорт тамашачысының яраткан артисты, Башкортстанның, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Салават Юлаев исемендәге бүләк иясе Нурия Ирсаева сәхнәгә чыгуга, зал аны алкышлар белән каршы ала. Ул уйнаган спектакльләр халык күңеленнән җуелмый.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

– Нурия ханым, сез күп кенә рольләрегез белән тамашачы күңеленә уелып калдыгыз. Үзегез сагынып яши торган рольләрегез дә бардыр?

– Мин аларның барысын да сагынам. «Айгөл иле»ндә – Айгөл, «Галиябану» спектаклендә – Галиябану, «Галия»дә – Галия, «Тапшырылмаган хатлар»да – Галия, «Зәңгәр шәл»дә – Мәйсәрә һәм башкалар. Соңгысында сигез халык җыры башкара идем. «Үзебез сайлаган язмыш»та Динә ролен бик яраттым. Яшь кенә булса да, зурларча фикер йөртә торган кыз. Ул рольләр әле дә булса минем төшләргә кереп йөдәтә.

– Сәхнәдә үз-үзегезгә куйган таләбегез...

– Әгәр үзем сөйли торган монологта ямьсез җөмләләр булса, мин беркайчан да аларны тамашачыга карап әйтмим. Начар кешеләр турында да тамашачыга карап сөйләүне яратмыйм. Театрга сәнгать яратучылар гына килә бит.

– Театр артистына җырлый белү дә зур бәхет бит әле.

– Әйе, миңа, ярты гасыр сәхнәдә эшләү дәверендә, партнерым Фидан Гафаров белән җырлы рольләр уйнарга насыйп булды. Әмма безне күп файдаланмадылар, дияр идем. Рифкат Исрафилов киткәч, ике-өч ел рольсез йөрергә дә туры килде.

– Ул чакларда Фидан Гафаров белән сезнең дуэтка сокланмаган кеше калмагандыр.

– Күп артистлар партнерсыз гомер кичерә. Фидан – минем бик яхшы партнерым булды. Туганымдай якын кешегә әйләнде. Гомер буе сәхнәдә җитәкләшеп йөрдек. Хәтта безне ир белән хатын дип кабул итүчеләр дә булды.

– Сәхнәдә партнерларыгыз белән кичергәннәрне тормышта кичерергә туры килмәдеме?

– Төрле кичерешләр булды. Тормышта яраткан кеше тарафыннан хыянәт тә, көнләшү дә күрдем. Яшь чакта нахак сүзләр йөрәкне әрнетә иде. Аннары әкренләп күнегә башладым. Беркайчан да «син минем турыда сөйләгәнсең» дип вакланып йөрмәдем.

– Әгәр гомер ике килсә, язмышыгызның кабатлануын теләр идегезме?

– Шул ук язмышны кабатласам да, кайбер нәрсәләрне үзгәртер идем. Әгәр артист һөнәрен сайласам, театрга шултикле бирелмәс идем. 50 яшьләрдә туктап, кабат укып, һөнәремне режиссерга алыштырыр идем. Ул эшне бик яратам мин.

– Режиссер дигәнлектән. Сез ярты гасыр буе төрле образларны үз йөрәгегез аша үткәргәнсез. һәр әсәргә үз карашыгыз бар. Үзегезгә спектакльләр куярга тәкъдим иткәннәре юкмы?

– Мин ун ел элек Стәрлетамакта – «Галиябану»ны, сигез ел элек Туймазыда «Яшь йөрәкләр»не куйган идем. «Галиябану»ны бүген дә уйныйлар, халык яратып йөри.

– Нурия ханым, Мәскәү киностудияләрендә «Возвращение чувств» һәм «Двое на голой земле» дигән фильмнарда да төшкәнсез. Аларны зәңгәр экраннардан караганда ничек кабул иттегез?

– Мин ул фильмда төшүнең алымнарын ахыргача аңлап җиткермәдем. Сәхнәдә уйнаганда бөтен көчеңне саласың, ә бирeдә экранга карап сөйләргә кирәк. Киноны караган чакта, ярыйсы гына килеп чыкканын күргәч, сөенеп куйдым. Әмма мин үземә һәрвакыт тәнкыйть күзлегеннән карыйм. Шулардан соң тагын ике фильмга чакырганнар иде, әмма гастрольләрдә булу сәбәпле, бара алмадым.

– Талантыгызга баш июче җитәкчеләр дә булмый калмагандыр. Сезнең яшәешегез белән кызыксынып, ярдәм кулы сузарга теләүчеләр булмадымы?

– Бервакытта да: «Син күп эшлисең, ярдәм кирәк түгелме?» – дигән сүз ишетмәдем. Үзем дә соранып йөрмәдем. Барысына да үз көчем белән ирештем.

– Бүгенге көндә җәмгыятьтә сезне нәрсә борчый?

– Тирә-юньдәге битарафлыкны куралмыйм. Кешеләрнең туң йөрәкле булуына борчылам. Үзем урамда исерек йоклап ятса да, аны барып уятуны да оятка санамыйм.

– Кызыгыз Гөлназда да сәнгатькә карата мәхәббәт уятмагансыз. Бүген ул нәрсә белән шөгыльләнә?

– Ул сигез ел театрда эшләгәннән соң китеп барды. Бүгенге көндә радиода режиссер һәм тавыш операторы булырак тапшырулар әзерли. Ике оныгым үсеп килә.

– Сезнең гастрольләрне Казан тамашачысы көтеп ала. Үзегез Татарстанга килгәндә, нинди хисләр кичерәсез?

– Безне, Казанга килеп төшүгә, һәрвакытта бөтен коллектив каршы ала. Һәрберебезнең дуслары бар. Үзем ахирәтем Наилә Гәрәева белән очрашкан саен, сәнгать турында сөйләшеп сүзебез бетми. Безнең театрлар кебек тату, дус коллективлар башка юк тыр ул.

ОСТА

Сәйлән тезәм сөенеп

Үз кулың белән эшләнгән бүләк һәрвакыт кадерлерәк, чөнки аңа бөтен җан җылыңны саласың. Балтач районы Чепья авылы кызы Гөлфинә Гыйльмуллина Казанның Яңа Савин районының 113нче мәктәбендә укытучы булып эшли. Буш вакытларында сәйләннән чәчәкләр ясап, якыннарын сөендерә. Татар теле укытучысының сәйлән белән мавыгып китүенә нәрсә сәбәп булган? Гөлфинә белән очрашкач та, шул сорауны бирдем.

– Үзем дә аңламый калдым. Авылга ялга кайткан идем, әнием: «Күрше Салаватка кереп кара әле, сәйләннән шундый матур итеп миләүшә чәчәкләре ясаган, сиңа ошаячак!» – диде. Кердем. Салават тимерчыбыкка сәйлән тезеп утыра. Ул 5нче сыйныфта укый иде. Миңа да чәчәкне ничек эшләргә кирәклеген аңлатты. Өйгә очып кайттым. Минем бәхеттән, өйдә сәйлән бар иде, ясап карарга булдым. Күрше малаеннан күреп чыккан миләүшәләрдән башладым. Ясадым да савытка утыртып куйдым. Ул вакытта ничек сөенгәнемне аңлатып бетерә торган түгел.

– Бу эштә иң беренче чиратта нәрсәгә игътибар итәргә кирәк?

– Чәчәкләрнең һәр тажы аерым чыбыкка тезелә. Шулардан чәчәкләрне җыясың, яфраклар үрәсең. Бөтен детальләре дә ясалып беткәч, зур бер композиция төзелә. Чәчәкләрне савытка утырту өчен гипс сатып аласың. Гипс эремәсе артык сыек та булмасын, шул ук вакытта катып китәргә дә тиеш түгел.

– Бик вак эш бит, ялыктырмыймы?

– Чыннан да, сәйләннән чәчәк ясау бик күп вакыт һәм сабырлык таләп итә. Сәламәтлеккә дә тәэсир итми калмый: күзләр арый, озакка китсә, арка авырта башлый. Шулай булуга карамастан онытылып эшлисең, үзеңчә тынычландыра да ул. Икенче бер дөньяга эләккән кебек буласың. Һәр ясаган чәчәгем үзем өчен бик кадерле. Бәйрәмнәргә сорап килүчеләр дә юк түгел. Кайвакыт бик биреп җибәрәсем дә килми.

– Идеяләрне кайдан аласыз?

– Тәрәзә төбендә үскән гөлләр, социаль челтәрдәге тәкъдимнәрдән...

– Сәйләннән кала, тагын нинди мавыгуларыгыз бар?

– Авылга кайткач, урманга барам. Аңлатып бетерә алмаслык хис, җиңеллек һәм тынычлык алып кайтам аннан. Минемчә, бер урында гына таптанмыйча, һаман алга омтылырга кирәк. Вакытны файдалы итеп үткәрү – минем төп максатым.

Сөмбел ХӘСӘНОВА,
Россия ислам институты студенты.

Әтиебез – нәселебез горурлыгы

Тарихи вакыйгаларга бай 1903 елның 15 маенда Ырымбур гөбернәсе Икенче Зубочистка авылында әтием Зыят Әхмәт улы Хәйбуллин туа. Өч яшендә үк ятим калган Зыятны авыл тәрбияләп үстергән. Ел дәвамында бер гаиләдә, икенче елны икенче гаиләдә булганнан соң, авылның бер саллы гына кешесендә тәрбияләнә башлый. Менә шунда гына ул ятимлекнең ни икәнен татый.

Зыят белемгә омтыла, авылдашы сизеп алып, үзенең улы белән бергә укырга авыл абыстаена илтә. Ул чорда авылларда мәктәпләр булмый һәм мөгаллимнәр балаларны үз өйләрендә укыталар. Ике дусның абыстай биргән сабакларны әйбәт үзләштергәннәрен белеп алган баерак абыйлары бу егетләрне Ырымбурдагы «Хөсәения» мәктәбенә урнаштыра.

Әлбәттә, укып кайткан тәрбияле егет Зыятка авылда шактый күп кызлар гашыйк булгандыр. Әмма аның йөрәгендә авылның беренче чибәре Гайшә генә була. Аларның бәхетле гаилә тормышы 62 ел дәвам итә. Ныклы гаиләдә бербер артлы дүрт бала дөньяга аваз сала. Бишенче нарасый ана карынында вакытта Бөек Ватан сугышы башлана. Сугышның беренче көннәрендә үк Зыят Әхмәт улына хәрби комиссариаттан чакыру кәгазе китерәләр. Шатлыгыбызга, кулына «бронь-справка» дигән кәгазь тотып, әтиебез кайтып төшә. Хәрби комиссариатта белемле кешеләрнең тылда да кирәк икәнлеген белгәннәр, ахрысы.

1941 елның 31 декабрендә колхозның алдынгы тракторчысы Зыят Хәйбуллинга бирелгән «бронь-справка»ның вакыты чыга. Шул ук көнне аңа чакыру кәгазе дә килә һәм егетләр Саракташ тимер юл станциясенә җыелалар. Күбесе үзләренең механикалаштырылган полкларга билгеләнүләре турында беләләр, ә менә фронтка китүче состав кузгалып китәргә нибары бер сәгать чамасы вакыт калганда, әтине аерым бүлеккә чакырып алалар һәм аны биредәге полковник адъютанты итеп билгелиләр.

Әткәй өч елдан артык башта Смоленск, аннан соң Сталинград янындагы каты сугышларда катнаша. Биредә ул яралана һәм контузия ала. Шушы елларда ул адъютант вазифасын башкарып, бүлек командирларын җәен автомашинада, кышын атлы чаналарда фронт сызыгы буенча йөртә.

Әткәй фронтта вакытта безнең өйгә өчпочмаклы солдат хатлары килеп торды. Аларны өлкән апаларыбыз әнкәй соравы буенча кат-кат укыйлар иде. Алар укыган саен, әнкәйнең йөзе ачыла тора иде, димәк, әткәй исән-сау һәм илне явыз дошманнан азат итешә! Әнкәйнең шатлануын күреп, аңлап бетермәсәм дә, алар белән бергә шатлана идем. Мин әткәйне туганнан бирле күргәнем булмады, чөнки мин, ул хезмәткә китеп, ике ай узгач, 1942 елның 8 мартында туганмын һәм минем аның белән тәүге очрашуым миңа өч яшь тулып узгач кына булды. Сугыш тәмам булып, әткәй исән-сау авылыбызга әйләнеп кайтты. Аны беренче тапкыр күрүем әле хәзер дә күз алдымда: әткәй хәрби киемдә, төптөз сынлы, әйтерсең лә әнкәй сөйләгән әкияттән чынбарлыкка әверелгән батыр. Әткәй миңа солдат каешы белән пилоткасын бүләк иткәч, җиде күккә ашкандай булдым. Каешны тиз генә буып, пилотканы киеп, ялан тәпи авыл урамы буйлап узганда, минем арттан тузан гына күтәрелеп калды.

Без алты бала өчен ул үрнәк булды. Берәр шуклык ясап куйсак, әткәй һичбер вакыт безгә тавыш күтәреп, кеше алдында орышмады. Аннан соң әткәй бервакытта да «булдыра алмаслык вәгъдә» бирмәде. Яхшылыкка – яхшылык. Шуңа күрә дә аны авылдашлары хөрмәт итеп, киңәшләшәләр иде. Хәтта берәрсе өйгә нигез саласы булса да, әткәй янына килеп, киңәшләшеп, дөрес урын сайлыйлар иде. Сугыштан күпсанлы орден-медальләр белән кайткан әткәй, ләкин ул бүләкләрен бер генә тапкыр да бәйрәмнәрдә тагып чыкмады. Әткәйнең тыйнаклыгын, аның: «Мин сугышта булдым!» – дип мактанып йөрмәвен авыл халкы да бик яхшы белә иде. Без, балалар, әткәйнең орден-медальләре белән уйный торган идек, күпмесе югалып бетте. Ул бүләкләрнең кыйммәтлеген, күпме кан коеп яулап алынганын белмәгәнбез шул.

Әткәй беркайчан да төшенкелеккә бирелмәде, бәетләр чыгарып, иҗат итеп яшәде. Хәтта Казанның югары уку йорты галимнәре дә әткәй чыгарган бәетләргә югары бәя бирделәр.

90 яшен билгеләп узганнан соң бакыйлыкка күчкән хөрмәтле әткәй рухы алдында без, барыбыз да югары белемле белгечләр булып җитешкән балалары, тез чүгеп, башыбызны иябез. Әткәй, безгә биргән тәрбияң өчен рәхмәт. Синең белән без генә түгел, оныкларың, оныкчыкларың, нәселебезнең барлык дәвамчылары горурланачак!

Шәриф ХӘЙБУЛЛИН,
Бөек Ватан сугышы ветераны улы.
Казан шәһәре.

Һәр балага шундый әти кирәк

«Кызым, беркайчан да онытма: иң авыр, иң уңышсыз чагыңда да сине өйдә һәрчак көтәләр, аңлыйлар һәм яраталар», – дип, әтием миңа кечкенәдән әйтеп килде. Мин бу сүзләрнең мәгънәсен элегрәк аңлап җиткермәгәнмен, әмма әти-әнием янында калага укырга киткәч, ниһаять, асылына төшендем. Әтием кеше күңелен аңлый торган кече күңелле психолог минем. Тик һөнәре түгел, ә тормышны аңлавы, күзаллаулары буенча. Аның хәтта бер җөмләсе дә күңелдә ышаныч уята, мондый мизгелләрдә авырлыклар белән ялгыз булмавыңны аңлыйсың.

Әтием – Искәндәр Мосавир улы Нигъмәтҗанов – 1970 елның 12 сентябрендә Сарман районы Ютлимер авылында дөньяга килгән. Кечкенәдән авылны яраткан, техника белән кызыксынган. Башка малай-шалайлар кебек үк, мәктәптә укырга яратмаган, үскәч шофер булу турында хыялланган. Ә 8нче сыйныфтан соң Сарманның һөнәр училищесына укырга кергән. Әтием – җир кешесе. Училищены тәмамлаганнан соң, ул авылына кайта һәм басу-кырларыннан, комбайн-тракторыннан бер генә мизгелгә дә аерылмыйча яши башлый. Әле 17 яше дә тулып җитмәгән егеткә колхоз рәисе, ышанып, «Алтай» тракторы бирә, шуның белән эти җир эшкәртә. Ә аннан соң өч елга хәрби сафларга флотка алалар. Әлбәттә, армия аның өчен зур тормыш мәктәбе була: күп нәрсәгә өйрәтә, яңа киңлекләр күрсәтә. Тик аннан кайткач та әтием, шактый тәҗрибәле булуга карамастан, үз авылын, туган җирен ташлап китми, яраткан эшен дәвам итә. Бүгенге көнгәчә тимер атын иярли. Тырыш хезмәтенең нәтиҗәләре булып аңа бирелгән грамоталар һәм бүләкләре тора. Көннәр буе эштән арып-талып кайтса да, ул безнең белән булырга һәрчак вакыт таба иде. Апам белән миңа кечкенәдән басу-кырларны күрсәтергә яратты. Язлар җитеп, ташу китсә, без якын-тирәдәге авылларны карарга бардык. Күпер астында ярсып аккан ташкынга карап, без, ирекле кошлар кебек кулларны җәеп, уйдан гына йөзеп китә идек… Әтинең кече күңелле булуын мин хәзер генә аңлыйм: ул безгә беркайчан да юк дип әйтмәгән, балаларын бәхетле итәр өчен бар көчен куйган, үзе күргән матурлык белән бүлешергә теләгән. Ямьле җәйләрдә без себерке, җиләк җыярга да әти белән йөрибез. Ул безгә һәрвакыт ниндидер кызыклы вакыйгалар сөйли, табигатьнең матурлыгын, ерактагы киңлекләрен күрсәтә, тау башыннан кечкенә генә бер тап булып күренгән авыллары белән таныштыра. Хәтта басу юлында туктап, узыша-узыша йөгерешә идек әле без!

Әтием бик шук, җор телле кеше дә әле минем. Авыл баласы гына булуына карамастан, һәр сүзен уйлап әйтә, үз фикерен кешегә мәҗбүриләп такмый, ә тыныч кына тәкъдим итә. Аз сөйләшсә дә, һәр сүзенең мәгънәсе бар. Аның уйлары да һәрчак дөреслеккә туры килә! Әтием чын мәгънәсендә укымышлы, гыйлемле кеше минем. Китап-журналларны бөртекләп укый, тикшерә, анализлый һәм бер ишеткәнен инде кабат онытмый да. Безнең өйдә буш вакытларда китаплар турында фикер алышу була. Гадәттә, әти үзе укыган берәр нәрсәне шундый кызык, рәхәт итеп сөйли, соңрак без дә, аннан калышмаска тырышып, йотлыгып теге китапны укып чыгабыз. Мәктәпкә кергәч тә, югары сыйныфларга җиткәч тә, әти безгә өй эше әзерләргә һәрвакыт ярдәм итте. Мин беренче сыйныфта укыганда икебез бергә ятлаган русча шигырьне әле һаман да онытмыйм. Башка фәннәрдән дә, әти эштән кайткач, апам белән ярыша-ярыша, бирелгән өй эшләрен сөйли идек. Һәрчак сөйләм фәннәрен, биология, тарих, география, химия, физикаларны әти белән укыдык. Мин һәрчак аптырый идем: әтием моның кадәр күп әйберне каян белә икән?! Апамның да, минем дә мәктәпне алтын медальгә тәмамлавыбызда әтиебезнең дә өлеше бик зур дип саныйм.

Холкы буенча сабыр ул. Тавышын күтәрмәсә дә, кушкан эшләрен, аның сүзен без һәрчак тыңларга тырышабыз. Аңа каршы сүз әйтү яки аны тыңламау – болар безнең өчен түгел. Малайлары булмаса да, әтием безнең белән горурлана аладыр дип уйлыйм: без аңа һәрчак булышырга тырышабыз, хәтта кайбер егетләр белми торган эшләрне дә эшләшәбез.Ул безне техника серләренә дә өйрәтте. Апам машина йөртү буенча республикакүләм ярышларда катнашып, призлы урыннар алды. Ә аны әзерләүче кеше – әтием булды.

Ул бик ярдәмчел кеше. Авыл халкы алдында да аның абруе зур. Йомыш белән кергәннәрне бервакытта да кире борып чыгармый. Аның ясаган тагылма кораллары белән бүгенге көндә дә үзебезнең авыл халкы гына түгел, хәтта күрше авыллар да файдалана. Аның кебек миһербанлы, саф күңелле әтиләр һәр балада булсын иде!

Айсылу НИГЪМӘТҖАНОВА,
Сарман районы,
Ютлимер авылы.

«Тукай – ядкярләрдә» хакындагы фикерләр

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай (1886-1913) тууына 130 ел тулу алдыннан, 2015 елда «Җыен» фонды ике томлы «Тукай – ядкярләрдә» (гомуми бит саны 1688) дигән хезмәт бастырып чыгарды. Анда барлыгы 670 берәмлек материал тупланган. Шуларның 599 берәмлеге гарәп һәм латин хәрефләрендәге чыганаклардан гамәлдәге татар алфавитына күчерелеп урнаштырылган. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты Гыйльми советы 10 февральдә бу хезмәтнең автор-төзүчеләре филология фәннәре докторы Р.Ф. Исламов һәм Тарих фәннәре кандидаты Җ.С.Миңнуллинны 2017 ел өчен Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә бертавыштан тәкъдим итте. Шул уңай белән Россия Федерациясенең төрле төбәкләреннән һәм якын чит илләрдән шактый бәяләмәләр, хуплаулар килде. Бүген «Шәһри Казан» үзенең укучыларын аларның кайберләре белән таныштыра.

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕНӘ КАНДИДАТ

***

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай (1886-1913) башкорт халкына да бердәй кадерле. Чөнки безнең күп буын әдипләребез аның иҗат мәктәбендә тәрбияләнде һәм үсте. Алай гына да түгел, ул Уфа шәһәренә килә, Башкортстанның халык шагыйре Мәҗит Гафури (1880–1934) белән шәхси дуслыкта була. 1936 елдан башлап хәзерге вакытка кадәр аның әсәрләре башкорт теленә тәрҗемә ителә.

«Шәхесләребез» сериясендә ике томлы «Тукай – ядкярләрдә» (Казан: Җыен, 2015) дигән фәнни-популяр басма өчен филология фәннәре докторы Рәмил Фәнәви улы Исламов һәм тарих фәннәре кандидаты Җәүдәт Сәлим улы Миңнуллин 2017 ел өчен Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителүен зур канәгатьләнү белән хуплыйм.

Бу ике томлык Тукайның тормышын һәм иҗатын, ХХ йөз башы татар һәм башкорт мәдәниятен өйрәнүгә бибәһа өлеш булып тора. Чөнки андагы күп материаллар һәм шәхесләр шулай ук Башкортстан белән дә бәйле. Автор-төзүчеләрнең тырышлыгын һәм хезмәт сөючәнлеген һәм аларның әлегә кадәр билгеле булмаган архив материаллары, ХХ гасыр башы гарәп һәм латин графикасындагы көндәлек матбугат материаллары белән җентекле, тәфсилле эшләүләренә соклану белән сөенәм. Бу безгә элек белгән шагыйребезне бөтенләй башкача күзалларга ярдәм итә.

Бу титаник хезмәт өчен Р.Ф. Исламов һәм Җ.С. Миңнуллин, һичшиксез, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек дип саныйм.

Ногман Мусин, Башкортстан Язучылар берлеге әгъзасы, БАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Салават Юлаев исемендәге республика премиясе лауреаты, Башкортстан Республикасының халык язучысы.

* * *

Филология фәннәре докторы Рәмил Фәнәви Исламов һәм тарих фәннәре кандидаты Җәүдәт Сәлим улы Миңнуллин тарафыннан «Шәхесләребез» сериясендә ике томлы «Тукай – ядкярләрдә» дигән хезмәт татар әдәбияты тарихына һәм Тукайны өйрәнү фәненә бәһаләп бетергесез өлеш булып тора. Тукайның Уральски чорына караган чыганаклар да материалларның шактыен тәшкил итә.

Татарстан галимнәре тарафыннан масштаблы эш башкарылуын билгеләп үтү зарур. Ул шигърият һәм әдәбият сөючеләр арасында гына түгел, ә үзенең тарихына, мәдәниятенә һәм теленә хөрмәт белән караган Татарстан Республикасы халкында киң соралган хезмәт булачак.

Бу уңайдан Р.Ф. Исламов һәм Җ.С. Миңнуллинның ике томлы хезмәте Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек дип саныйбыз һәм алга таба галимнәрнең берлектә эшләве шагыйрь Габдулла Тукай тормышының яңа сәхифәләрен ачу мөмкинлеге бирер.

Әсгать Нускабай, Казахстан Республикасының Казан шәһәрендәге Баш консуллыгының Баш консулы.

* * *

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның (1886-1913) тормышы һәм иҗаты язучылар, галимнәр, рәссамнар, артистлар һ.б. өчен бетмәс илһам чыганагы булып тора. Бу уңайдан филология фәннәре докторы Рәмил Фәнәви улы Исламов һәм тарих фәннәре кандидаты Җәүдәт Сәлим улы Миңнуллинның «Шәхесләребез» сериясендә нәшер ителгән «Тукай – ядкярләрдә» дигән ике томлыгы Тукайны һәм татар әдәбияты белемен өйрәнүдә җитди казаныш булып тора. Р.Ф. Исламов һәм Җ.С. Миңнуллинның бу хезмәте Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек дип саныйм.

Фиринат Халиков, Россия сәнгать академиясенең мөхбир-әгъзасы, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, федераль дәүләт бюджет «Казан шәһәрендәге Россия сәнгать академиясе каршындагы рәсем сәнгате иҗат остаханәсе» директоры.

***

Республикабызда татар мәдәниятен үстерүне максат итеп куйган «Җыен» фонды 2015 елда «Шәхесләребез» сериясендә «Тукай – ядкярләрдә» дигән ике томлы хезмәт бастырып чыгарды (төзүче-авторлары филология фәннәре докторы Рәмил Исламов һәм тарих фәннәре кандидаты Җәүдәт Миңнуллин). Гомуми күләме 1688 биткә тупланган материал гаять эчтәлекле һәм кызыклы. Дөрес, Тукайга багышланган язмаларның нәшер ителгәннәрен генә җыйнап чыгарсаң да, шактый күләмле булыр иде. Әмма әлеге ике томлыкның үзенчәлеге шунда ки, андагы материалның 80-90 проценты беренче мәртәбә бастырыла! Ә бу – җентекле эзләнүләр, ифрат күп көч таләп итә торган эш. Ул – Тукайның дәвамлы мирасын дөньяга күрсәтүдә әһәмиятле басма. Шик тә юк, бу ике томлык әлеге минем хыялымдагы «Тукай китапханәсе»нең иң түрендәге шүрлектә урын алыр иде.

Тукайның үз исемендәге Татарстан Республикасының Дәүләт премиясенә нур өстенә нур булырлык хезмәт бу. Әлеге мәртәбәле бүләк буенча комиссия дә нәкъ шул фикердәдер, дигән зур ышаныч бар.

Гәрәй Рәхим, Татарстанның халык язучысы, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

Мин беләм: ул иң кирәклесе

✓ «Тупла» кертеме
Керемнәрнең ышанычлы төстә үсүе: югары процент булган счет ачыгыз

✓ «Идарә ит» кертеме
Финанслар белән иркенрәк рәвештә һәм җиңел идарә итегез

✓ «Уңайлы мизгелне ычкындырма» кертеме
Кыска вакыт эчендә югары процентлар

Тулырак мәгълүматны 8-800-2005-303 телефоны аша (Россия буенча шалтрату бушлай) һәм www.akbars.ru сайтында белеп була.

АК БАРС БАНК

«АК БАРС» БАНК ААҖ РФ ҮБ Генераль лицензиясе 2590 12.08.2015 ел

Реклама

Милләтләрне шагыйрьләр дуслаштыра

Узган ел бөек Тукайның 130 еллыгын бәйрәм иткәндә, Республика балалар китапханәсе «Тукай дөньясына сәяхәт» дигән Бөтенроссия акциясе уздырган иде. Әлеге акциянең максаты, аңлашылганча, Русиянең төрле төбәкләрендә яшәүче балаларны татар халкының олуг шагыйренең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштырып, милләтебезгә хөрмәт уяту.

Акциядә Русиянең 19 төбәге актив катнашкан. Башкортстан, Чувашия, Мордовия, Удмуртия, Мари Эл, Калмык, Чечня, Алтай, Бурятия республикалары, Оренбург, Саратов, Курган, Чиләбе, Владимир, Свердловск, Ростов, Мәскәү һәм Түбән Новгород өлкәләре һәм Хабаровск крае балалары Тукай иҗаты белән танышканнар. Илнең 302 китапханәсе үткәргән чараларда 12052 малай һәм кыз Тукай иҗаты белән танышкан. Барлык катнашучыларга да дипломнар һәм Татарстан Халыклар дуслыгы йортының Рәхмәт хаты җибәрелгән.

Бу эштә төбәкләрнең татар мәктәпләре, аларның укытучылары, хәтта балаларның әби-бабайлары да нык булышкан. Мондый чара үткәргәнче, китапханәләрдә шагыйрь әсәрләреннән күргәзмәләр, портретын куеп, почмаклар ясалган. Балалар Тукай шигырьләрен кычкырып укып кына калмаган, яттан өйрәнеп, ярышлар да уздырган, сәхнәләштергәннәр дә. Башкортстанның Стәрлебаш район китапханәсе хәтта Тукайның кечкенә генә музеен да оештырган. Бу көннәрдә Тукай әсәрләре рус, татар, башкорт, чуаш, мари, инглиз, немец телләрендә «сөйләшкән». Тукайны чит ил телләрендә укытучылар үзләре кычкырып укыган. Башкортстанның Бишбүләк район китапханәсендә Тукай шигырьләре чуаш телендә дә яңгыраган – бу районда чуашлар күпләп яши. Тукай әкиятләренә нигезләнеп ясалган мультфильмнарны карау да балалар өчен көтелмәгән сөенеч булган. Татар балалары мондый бәйрәмнәрне гадәттә «Туган тел»не җырлап тәмамлаганнар. Кайбер китапханәләрдә Тукай шигырьләрен укып, өйрәнеп кенә калмаганнар, бергәләп татар халык уеннары да уйнаганнар. Түбән Новгород өлкәсенең Канава районы китапханәсендә балалар Тукай балачакта яратып уйнаган «Тимербай», «Түбәтәй» уеннарында актив катнашканнар. Кайбер китапханәләр мөмкинлекләре чикләнгән балаларны да бу мөһим эшкә тарту юлын тапкан. Начар күрүче сабыйлар «Шүрәле» китабын бармаклары белән тотып өйрәнгәннәр.

Кайбер төбәкләрнең китапханәләрендә мондый чаралар балалар өчен генә түгел, барлык халык өчен дә зур бәйрәмгә, олы вакыйгага әйләнгән. Башкортстанның Баймак районы үзәк китапханәсенә китап укырга Бөек Ватан сугышы ветераны – 91 яшьлек Гайзулла Аблюзин килгән. Ул балаларга Тукайның «Ятимә» шигырен сөйләгән. Шагыйрьнең бу шигырен аксакал 1938 елда ук ятлап, авыл клубы сәхнәсеннән сөйләгән булган һәм хәзергә кадәр аны хәтерендә саклаган. Шул ук Башкортстанның Янурыс авылы китапханәсенә авылның әк әбисе – 83 яшьлек Наҗия апа Ямилова да килгән һәм Тукайга багышлап язган шигырьләрен укыган.

Бик күп җирләрдә балалар Тукай исемен беренче тапкыр ишетеп, үзләре өчен яңа, зур шагыйрь ачканнар, аны үз милләтләренең шагыйрьләре белән чагыштырганнар. Калмык Республикасы балалары да Тукай турында беренче тапкыр гына ишетсәләр дә, Кырлайның матур табигатендә милли эпослары «Җангар»дагы сурәтләүләр белән уртаклык тапканнар. Калмыкларның Шүрәлегә охшаган әкият геройлары – Шулмус та бар икән. Китапханәчеләр әлеге әкият геройлары аша явызлыкның бик начар нәрсә булуын аңлаткан һәм балаларны татар шагыйре Тукай һәм калмык шагыйре Давид Күгелтиновтан үрнәк алып, яхшы кешеләр булып үсәргә өндәгәннәр. Башкортстан укучылары Тукайны үзләренең зур шагыйрьләре Мостай Кәрим белән чагыштырып өйрәнгәннәр. Кайда гына яшәсәләр дә, балалар Тукай шигырьләрен бер укуда яраткан. Аларның гадилеге һәм шул ук вакытта серлелеге җәлеп иткән. «Шүрәле» китабының 15 телгә тәрҗемә ителүе дә шаккатырган.

Республика балалар китапханәсенә төрле төбәкләрдән күп кенә рәхмәт хатлары да килгән. Алтай краеннан: «Мондый чара өчен бик зур рәхмәт, без үзебезне күпмилләтле зур Россия гаиләсендә бердәм итеп тойдык», – дип язганнар. Бик күпләр Татарстан мәдәнияте, әдәбияты белән башланган кызыксынуларын башка милләт әдипләренә дә күчергәннәр. Шактый гына моңа кадәр билгеле булмаган фактларны да хәбәр иткәннәр. Мари Элның Бәрәңге бистәсендә иң матур урам Тукай исемен йөртә икән. Түбән Новгород өлкәсе Спас районында Тукай авылы бар. Боларны белү горурлануны тагын да арттырган.

Быел республикабыз китапханәләре калмык халкының танылган шагыйре Давид Күгелтиновның тууына 95 ел тулуга багышланган Бөтенроссия акциясендә катнаша. Әлеге тәкъдим белән Калмык Республикасының милли китапханәсе чыккан. 13 март – шагыйрьнең туган көнендә бөтен Россия китапханәләрендә аның китапларын кычкырып уку үткәрелгән. Бу замана балаларында китапка мәхәббәт уятырга гына түгел, милләтләр арасындагы дуслыкны ныгытырга да булышачак. Ә дуслык ул – тынычлыкның нигезе.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Кабан күле элек-электән иң серле күлләрнең берсе булып санала. Аның турында тарихи чыганакларда да мәгълүматлар күп. Беркөнне кулыма 1936 елда латин графикасы белән басылган «Техника» журналы килеп керде. Анда язучы Хәмит Кави Кабан күлен саклау, аны чистарту проблемасын күтәреп чыккан булган. Кайбер фикерләр бүгенге көн белән дә аваздаш.

Кабан күле серләре

КАЗАННЫ АЧУ

Кабан күле буенда «Спартак», «Кызыл Шәрык», СК-4 заводлары һәм башкалар урнашкан. Казан электр станциясе Кабан күле суыннан файдалана. Электр станциясенә су җитмәү проблемасы сизелә. Шуңа да киләчәктә, Кабан күленең суын арттыру өчен, кайбер гидротехника эшләре үткәрелергә тиеш. 1935 елның язында күлдә геолог Мәҗит Кави җитәкчелегендә инженерлык гидрогеология тикшерүләре уздырылды», – дигән Хәмит Кави.

Кабан күленең озынлыгы турында да мәгълүматлар бар: «Кабан күле өч кисәктән тора. Аның шәһәр эчендә урнашкан урынын Түбән яки Якын Кабан дип йөртәләр. Урта Кабан тимер юлның СК-4 оешмасы ягында урнашкан. Борисково авылы янындагы күлне Югары яки Ерак Кабан дип йөрткәннәр. Түбән Кабан бер яктан – Казан ханлыгы заманасында казылган Болак аркылы Казансу елгасы белән, икенче яктан – тар бер бугаз аркылы Урта Казан белән тоташкан. Түбән Кабанның Болактан бугазга кадәр озынлыгы – 1,85 километр. Иң киң җире Күн техникумы янында булыр – 325 метрга җитә. Иң тирән җир – «Кызыл Шәрык» заводы каршында булыр – 15,5 метрга җитә. Урта Кабанның озынлыгы 3100 метр». Бу заводларның бүген күбесе булмаса да, кайда урнашкан булуларын чамаларга мөмкин.

Кабан күленең килеп чыгышы элек-электән сер булып кала бирә. Бу хакта галимнәр дә уйланган. Хәмит Кави язмасында әйтелгәнчә, кайбер галимнәр аны Иделнең элеккеге юлыннан калган сулык дип аңлата. 1935 елда, Түбән һәм Урта Кабанның төбен өйрәнү өчен, 5тән 15 метр тирәнлектә 55 урында бораулап казу эшләре үткәргән булганнар. Тикшерүләрдән ачыкланганча, күлнең төбе йомшак һәм ябышкак материаллардан тора. Әмма тикшерү вакытында бу катламнарны үтеп керә алмаганнар. Кабан күленең суы явымнар һәм Идел суының язгы ташу нәтиҗәсендә артып тора икән. Күлне су белән баетып торган чишмәләр турында да фикерләр булган, ләкин галимнәр моны расламаганнар. «Кабан күлен чиста тоту – халыкның төп бурычы», – дип тәгълләгән мәкаләсен Хәмит Кави. Мин дә язмамны шул сүзләр белән тәгәллисем килә. Сулыкларны карап тору – изге гамәл.

Равилә МӨБАРӘКШИНА,
Казан.

РОСКОМНАДЗОР КИСӘТӘ!

«Шәхси мәгълүматлар турында»гы Федераль закон нигезендә, шәхси мәгълүматлар эшкәртүне башкарып та, Шәхси мәгълүматларны эшкәртү Реестрында теркәлмәгән операторлар ТР буенча Роскомнадзор идарәсенә **белдерү хаты җибәрергә тиеш,** ә инде **2015 елның 1 сентябреннән,** «Россия Федерациясенең информацион-телекоммуникация челтәрләрендә шәхси мәгълүматларны эшкәртү тәртибенең төгәллеген тикшерү өлкәсендә кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 242-ФЗ санлы Федераль законның (21.07.2014 кабул ителгән) 2 маддәсе нигезендә, өстәмә рәвештә, РФ гражданнарының шәхси мәгълүматлары саклана торган мәгълүмат базасы урнашкан урынны күрсәтергә кирәк булачак (Казан, Гарифҗанов урамы, 28а йорт, 420138, а/я 25). Роскомнадзор шулай ук реестрда 2011 елның 1 июленә кадәр теркәлгән операторлар өчен оператор турындагы мәгълүматларга **үзгәрешләр кертү хакындагы документ** формасының үзгәртелүе (гадиләштерелүе) турында хәбәр итә. Шул ук вакытта операторларга 242-ФЗ санлы Федераль законның (21.07.2014 кабул ителгән) 2 маддәсе таләбе буенча, **2015 елның 1 сентябреннән,** РФ гражданнарының шәхси мәгълүматлары саклана торган мәгълүмат базасы урнашкан урын хакында мәгълүмати хат юлларга кирәк булачак. Тулырак мәгълүмат – **http://16.rkn.gov.ru/** һәм **http://pd.rkn.gov.ru/** сайтларында.

Бөтен кызыклы мәгълүмат бер урында
www.shahrikazan.com

КЛИНИКА ИНСАЙТ
КАЗАНЬ
Н.ЧЕЛНЫ
АЛЬМЕТЬЕВСК
ПЬЕТ БЛИЗКИЙ ЧЕЛОВЕК?
ПОМОЖЕМ КРУГЛОСУТОЧНО!
Вывод из запоя на дому
Вывод из запоя в стационаре
Бесплатная доставка в стационар
по Татарстану
РЕКЛАМА
ins-clinic.ru 8 800 505 02 74
Бесплатный звонок по России
имеются противопоказания, необходима консультация специалиста

«ЗАО «Камдорстрой Автобаза-48» требуются водители кат. С, D, E,
машинисты автокрана. Вахтовый метод, з/п сдельная.
Тел.: 8-937-581-22-01, 8-906-117-15-12 (водители), 8-919-632-58-60 (автокрановщики), (8552) 46-67-18.
РЕКЛАМА

Казан туристларга яңача ачыла

Май бәйрәмнәренә Татарстан башкаласы кунаклар өчен үзенчәлекле маршрутлар әзерләде.

Казан туристларны җәлеп итүе ягыннан Россия шәһәрләре бишлегенә керә, моны кунакларның саны арта баруы да раслый. Май бәйрәмнәренә ике атна вакыт калды, әмма инде бүген үк иң үзенчәлекле маршрутлар сайларга һәм Казанның бөтен үзенчәлекләре белән танышырга мөмкин. 2016 елның февралендә «Казанның туристлык-мәгълүмат үзәге» махсус экскурсия маршруты булдырган иде. Бер ел эчендә генә дә 600дән артык кеше әлеге үзенчәлекле маршрут буйлап сәяхәт кылды. Казанлылар һәм шәһәр кунаклары шәһәрне бөтенләй яңа яктан ачты. Алар күзәтү мәйданчыгына күтәрелеп, башкалабызның матурлыклары белән хозурланды, кунакчыл чәкчәк музеенда татар музыкасын тыңлап ләззәтләнде, балчыктан милли сувенир ясап, ерак тарихка сәяхәт кылды, татар авылында милли аш-сулардан авыз итте, «Арыш Мае» музей-кибетендә хуш исле эчемлекләрне татып карады.

Бу экскурсия маршрутындагы соңгы пунктка аеруча җентекле якын килделәр. Кибеткә керер алдыннан ук сез барлык вак-төякләрнең дә исәпкә алынуына игътибар итәчәксез. Туристларны йөртә торган автобуслар өчен махсус туктылыш бар, кирәкле транспортны эзләп баш ватарга кирәкми. Селфи һәм төркем белән фотога төшерә яратучылар өчен «Мин Казанны яратам» дигән стела урнаштырылган. Әмма иң кызыклысы – кибетнең эчендә. Пыяла гөмбәз астындагы үзәк зал Бөек Ханның баш киемен хәтерләтеп тора, ә таш идәндәге мозаика символлар аша Идел Болгарстанының тарихы хакында бәян итә. Биредәге сатучы-консультантлар, бүләккә сувенир сайларга ярдәм итү белән бергә, «Татспиртпром» АҖ компаниясенең бай ассортименты хакында да сөйләячәк. Продукциянең бай ассортименты, сыйфаты, үтемле бәяләр – боларның барысы да туристларның гадәти сувенирлар турындагы күзаллауларын үзгәртә. Алар магнит, брелок, милли бизәкләр төшерелгән савыт-саба да булырга мөмкин. Бүләкне сайлаганда, һичшиксез, дегустация дә каралган. Моның өчен ике зал эшли, аларның берсе – салкын «Хан бүлмәсе», анда температура +8 градустан да югарырак күтәрелми. Залга керер алдыннан кунакларга милли бизәкләр төшерелгән, мехтан тегелгән җылы кофталар бирәләр. Икенче зал күпкә иркенрәк тә, җылырак та, дегустациянең төп өлеше биредә уза. Монда сезгә Урта Идел буенда яшәүче халыкларның төрле эчемлекләрне ничек кулланулары хакында сөйләячәкләр, бүләккә дигән уникаль продукцияне үз күзләрегез белән күрәчәксез.

– Без туристлык сезоны башлануын түземсезлек белән көтәбез. Казанның Сәлимҗанов урамындагы кибеттә хезмәткәрләрнең өс киемен үзгәрттек, хәзер башкалабыз кунакларын милли костюмнар кигән хезмәткәрләр каршы алачак. Дегустация мәсьәләсендә дә яңалыклар бар. Хәзер кабымлык сыйфатында күркәдән әзерләнгән карпаччо яки пешкән алма белән ысланган казга заказ бирергә мөмкин. Әмма май аенда булачак иң көтеп алынган вакыйга – җитештерү процессының интерактив макеты. Хәзер ул – урнаштыру стадиясендә, – ди «Арыш Мае» сәүдә челтәре дирекциясенең коммерция директоры Татьяна Кручинина.

Узган ел әлеге үзенчәлекле маршрут «Шәһәрдәге иң яхшы маршрут» номинациясендә Бөтенроссия туристлык премиясе Гран-приена лаек булды.

Май бәйрәмнәрендә күпләр табигатькә чыга, шашлык кыздыра, бу – ир-атларның күңеленә аеруча хуш килә. Аларга гадәти булмаган бүтән төрле ял табылмас идемени? «Казанның туристлык-мәгълүмат үзәге»ндә әлеге мәсьәләне хәл итү юлларын таптылар, аннан теләгән һәркем файдалана ала. Бу – «Казан – чын ир-егетләр һәм аларның юлдашлары өчен!» дигән интерактив маршрут. 2017 елда узачак Конфедерацияләр Кубогы һәм 2018 елда көтелгән Футбол буенча дөнья чемпионаты алдыннан ул иң популяр маршрутларның берсенә әверелер дип көтелә. Кунакларны Россиянең өченче башкаласы саналган Казанның фәнни-техник, спортта ирешкән казанышлары, «Казан Арена» стадионы белән таныштырачаклар. Туристлык программасының ахырында экскурсантларга Татарстанның әйдәп баручы җитештерүчеләреннән берсе булган предприятиенең музей-кибетендә чын ир-ат эчемлекләренә дегустация уткәрәчәкләр. Биредән бер генә турист та буш кул белән китмәячәк. Эш шунда ки, татарларда берәр мәҗлескә, бәйрәмгә килгән кунакка кучтәнәч биреп җибәрү гадәте бар. Хәзер инде безнең кунакчыллыгыбыз һәм юмартлыгыбызны бөтен Россиядә, хәтта чит илләрдә дә беләчәкләр.

РЕКЛАМА

АФИША
17-23 АПРЕЛЬ

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

18 апрель «Палата №6» (А.Чехов)
КДМИ студентларының диплом эше
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 100 сум
19 апрель «Без китәбез, сез калысыз» (Т.Миңнуллин)
КДМИ студентларының диплом эше
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 100 сум
19 апрель «Сөясеңме, сөймисеңме...» (Ф. Бүләков)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 100 сум
20 апрель «Ак калфагым төшердем кулдан» (И.Юзеев)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
21 апрель «Иярләр» (Ә.Фәтхетдин)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 100 сум
КДМИ студентларының диплом эше
21 апрель «Бармы ришвәттән дәва?..» (З.Хәким)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
22 апрель «Дәрсе гыйбрәттер театр...» (Р. Мөхәммәтшин)
Башлана: 12.00
Билет бәясе: 300 сум
22 апрель «Дәрсе гыйбрәттер театр...» (Р.Мөхәммәтшин)
Башлана: 12.25
Билет бәясе: 300 сум
22 апрель «Әрем исе» (И. Зәйниев)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
22 апрель «Җәйнең бер көнендә» (Й.Фосе)
Башлана: 21.00
Билет бәясе: 300-350 сум
23 апрель «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев)
Башлана: 12.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
23 апрель «Искән җилләр көенә» (З.Хәким)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 250-1500 сум

«ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

19 апрель «Не хочу, не буду!»
Башлана: 11.00
21 апрель «Теремок»
Башлана: 11.00, 13.00
22 апрель «Не хочу, не буду!»
Башлана: 10.00
22 апрель «Теремок»
Башлана: 11.00, 13.00
23 апрель «Теремок»
Башлана: 11.00, 13.00
Билет бәясе: 250-600 сум

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

17 апрель «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов, Р.Заһидуллин)
Башлана: 18.30
18 апрель «Өченче булмәдә эт яши» (Р.Мингалим)
Башлана: 18.30
19 апрель «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов)
Башлана: 18.30
20 апрель «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.30
21 апрель «Алтын көз» (Ш.Фәрхетдинов, Р.Заһидуллин)
Башлана: 18.30
23 апрель «Ефәк баулы былбыл кош» (А.Гыйләҗев)
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 300-1000 сум

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ
(ПАВЛЮХИН УРАМЫ, 73)

21 апрель «Шаян концерт»
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 700-1100 сум
23 апрель Зифа Нагаева концерты
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 600-1200 сум

УНИКС
(ПРОФЕССОР НУЖИН УРАМЫ, 2/27)

19 апрель Васил‌ә Фәттахованы искә алу кичәсе
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 600-1200 сум
19 апрель «Зур концерт»
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 800-1300 сум

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

Язучы Марсель Галиевнең «ТЫНЛЫК ДӘШКӘНДӘ» дип аталган фотокүргәзмәсе
Керү ирекле (эш көннәрендә).

5+

Паспортсыз футбол карап булмый

СПОРТ

Конфедерация Кубогы матчларын карау өчен билет алу гына җитми, әҗанатар паспортын (FAN-ID) да булдырырга кирәк. Әлеге документ олыларда да, балаларда да булырга тиеш.

Стадионга кергәндә, паспорт тикшерү процессын тизләтә, чөнки документта җанатар турында барлык мәгълүмат та инде тупланган булачак. Чит ил кешеләре исә аның ярдәмендә беренче матчка ун көн кала Россиягә визасыз керә ала. Паспорт шәһәр эчендә транспортта бушлай йөрү мөмкинлеген дә бирә.

Җанатар паспортын Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Сочи шәһәрләрендә алып була. Казанда ул Бауман урамы, 44/8нче йорт адресы буенча бирелә. Документны почта аша да алып була.

– Конфедерация Кубогы башланырга ике ай вакыт калды. Һәр кеше дә паспорт алуны вакытында башкарса иде. Әлеге процесс нибары ике минут ала. Гаризаны интернет аша гына да тутырып була. Паспорт һәр кешегә бушка бирелә, – диде Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы беренче урынбасары Дмитрий Вандюков.

2017 елның 2 февраленнән инде 2000 җанатар паспорты тапшырылган.

ВОЛЕЙБОЛ. Европа волейбол конфедерацияләре (ЕКВ) кубогы өчен соңгы көрәш бара. Финал сериясендә «Динамо-Казан» белән Италиянең «Юнет Ямамай» (Бусто Арсицио) командалары матчы уза. Кубокка ия булу өчен Казан волейболчыларына ике партиядә җиңү яулау да җитә. Матч Италиядә 15 апрель көнне 19.00 сәгатьтә булачак. Ә берничә көннән волейболчы кызлар Россия чемпионаты матчында чыгыш ясаячак. 17-18 апрель көннәрендә «Динамо-Казан» Мәскәү «Динамо»сы белән очраша.

ФУТБОЛ. 15 апрель көнне, Россия чемпионаты кысаларында, «Рубин» «Краснодар» командасы белән очраша. Матч «Казан-Арена» стадионында 19.30 сәгатьтә узачак. Соңгы вакытта «Рубин» безне уңышлары белән сөендерми, шулай да бу матчка команданың баш тренеры Хавьер Грасиянең өмете зурдан.

– Сүз дә юк, узган матч нәтиҗәләре безнең кәефне төшерде. Ләкин без алда торган уенга күтәренке рухта әзерләнәбез. Хәзер команда бар игътибарын әзерлек эшенә юнәлтә. «Краснодар» белән уенга оптимистик рухта керәбез, – диде ул.

ХОККЕЙ. 15 апрель көнне «Ак Барс» җанатарларын сезон ябылышына чакыра. Команда белән формаль булмаган очрашу 14.00 сәгатьтә «Татнефть-Арена» боз сараенда узачак. Бәхет елмайган биш җанатар хоккейчыларның чишену бүлмәсенә керү мөмкинлеген отачак.

ЙӨЗҮ. Бөгелмә егете Александр Красных дөнья чемпионатында катнашачак. Бу көннәрдә ул 400 метр арага ирекле йөзү буенча Россия чемпионы булып танылды. 21 яшьлек спортчы бу аралыкны 3 минут 45,79 секундта йөзеп чыга. Әлеге күрсәткеч аңа дөнья чемпионатында катнашу хокукы бирә. Александр хәзер, түземсезлек белән, Будапешттагы чемпионатны көтә.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843). 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1642. Гомуми тираж – 6179.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 701. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843). 562-50-12,
факс: (843). 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы